**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 декабрендәге 5290 номерлы карары**

**Казан шәһәре Киров районының Горький Шоссесы урамындагы җир кишәрлекләренә ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2, 3 һәм 4 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 278 кв.м;
- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары 16:50:190402:1030 һәм 16:50:190402:1350;
- урнашу урыны: Казан шәһәре, Киров районы, Горький Шоссесы урамы;
- билгеләүнең максаты: инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен кирәкле «КЛ-0,4 кВ ТП-3771 кабель линиясе» электр челтәре хуҗалыгы объектын урнаштыру;
- билгеләү вакыты: 30 ел;

1.2. гариза бирүчеләр: «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләүнең нигезләре: гариза бирүченең мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы «Электр челтәре хуҗалыгы объектларының сак зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы, электр челтәрләренә технологик тоташтыруны башкару турында 2021 елның 9 декабрендәге 2021/КЭС/Т1197 номерлы килешү.

2. Сервитутны башкаруга бәйле рәвештә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаган яисә сизелерлек кыенлашачак вакыт 30 календарь көн тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут өчен түләү Россия Федерациясе Җир кодексының 39.46 статьясындагы 2, 3, 4, 5, 7 һәм 8 пунктлар нигезендә раслана дип билгеләргә.

4. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2, 3, 4 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның гамәлдә булу өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык

сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

5. Әлеге карарның 2 һәм 4 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

7. «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

7.1. әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренең хокук ияләре белән ачык сервитутны башкару турында килешү төзергә;


7.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән җир кишәрлекләрен, урнаштыру өчен ачык сервитут билгеләнгән инженерлык корылмасын төзү, капиталь яисә агымдагы ремонтлау, реконструкцияләү, эксплуатацияләү, консервацияләү, сүтү эшләре тәмамланганнан соң яки Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясындагы 2, 5 пунктларында каралган максатларда ачык сервитут билгеләнгән очракларда – җир кишәрлегендә тәэмин итү өчен ачык сервитут билгеләнгән эшчәнлек тәмамланганнан соң өч айдан да соңга калмыйча, рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану өчен яраклы хәлгә китерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 декабрендәге
5290 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Киров районының Горький Шоссесы урамындагы ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**





Масштаб 1:1000
Координаталар системасы: МСК-16

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:190402 | кадастр кварталы |
| 16:50:190402:1350 | Хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 декабрендәге
5290 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Киров районының Горький Шоссесы урамындагы ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре**




Масштаб 1:250
Координаталар системасы: МСК-16

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | гамәлдәге җир кишәрлекләре чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары |
| | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
| | капиталь төзелеш объектлары (мәйданлы) |
| 16:50:190402 | кадастр кварталы |
| 16:50:190402:1030 | Хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |